Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге Советының кырык икенче утырышы

Белкино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

23 май, 2025 ел № 113

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтен түләү турында» 2021 елның 9 апрелендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 9 апрелендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге Советы карарына (Белкино авыл җирлеге Советының 2022 елның 10 октябрендәге 49 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 65, 2024 елның 29 маендагы 92 номерлы, 2025 елның 31 гыйнварындагы 108 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1 пунктның 1.1 пунктчасында «19 173» санын «21 091» саннарына алмаштырырга;

1.2.1 пунктның 1.2 пунктчасында «13 990» санын «15 389» саннарына алмаштырырга;

1.3.1 пунктның 1.3 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Кушымтаның икенче абзацында «12,86» саннарын «15,48» саннарына алмаштырырга;

1.5. Кушымтаның 6 пунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Белкино авыл җирлеге башлыгы А.Н. Меньшов